СОВЕТ МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

с. Майдан

16.12.2015　　　　　　　　　　№ 4-27

## 2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге бюджеты турында

Статья 1

2016 елга Мәйдан авыл җирлеге (алга таба - Җирлек) бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) җирлек бюджеты керемнәренең гомуми күләме 2931,5 мең сум күләмендә;

2) Җирлек бюджет чыгымнарының гомуми күләме 2931,5 мең сум.

3) Җирлек бюджет дефицитының чикле күләме суммасында 0 мең сум.

2. Җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түбәндәгечә билгеләргә:

- 2015 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

Статья 2

1. 2016 елның 1 гыйнварына муниципаль бурычның өске ягын муниципаль бурычның эчке чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 сум күләмендә, бурыч йөкләмәләре буенча билгеләргә.

2. Җирлек муниципаль бурычының чикле күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

- 2016 елда - 0 мең сум күләмендә;

Статья 3

Җирлек территориясенең бюджетында 2016нчы елга керемнәр нең фаразлана торган күләмнәрен, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

Статья 4

Югары Ослан муниципаль районының бюджеты һәм 2016 елга Җирлек бюджеты арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

Статья 5

2016 елда Җирлек бюджеты муниципаль унитар предприятиеләр табышының бер өлешен, салымнарны түләгәннән соң калган һәм башка мәҗбүри түләүләрне исәпкә алып, 2016 елда бюджетка күчерү 2015елда алынган чиста табышның 20 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

Статья 6

1. Әлеге карарга № 4 нче кушымта нигезендә җирлек бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген расларга.

2. “Җирлек бюджет дефицитын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеген №5 кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 7

Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бүлүне расларга:

- 2016 елга әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә;

2. Җирлек чыгымнарының ведомство структурасын түбәндәгечә расларга:

- 2016 елга әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә;

Статья 8

Югары Ослан муниципаль районы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны исәпкә алырга:

- 2015 елда 2591,5 сум суммасында әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә

Статья 9

Җирлекнең муниципаль хакимият органнары 2016елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең һәм бюджет өлкәсенең башка оешмаларының санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Статья 10

2016 елда җирлек милкендәге һәм оператив идарәгә, мәдәният һәм сәнгать, сәламәтлек саклау, мәгариф учреждениеләренә, шулай ук архив учреждениеләренә

тапшырылган мөлкәтне арендага бирүдән керемнәр җирлек бюджеты керемнәре составына кертелә һәм бу карар нигезендә бюджет йөкләмәләрен үтәүгә файдаланыла дип билгеләргә.

Статья 12

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә җирлекнең бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

Статья 13

Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Статья 14

1. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында әлеге карарны урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы

Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В.В. Михеев